**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
ЧЕРЕМШАНСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН
**СОВЕТ КАРАМЫШЕВСКОГО**
**СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ**
Улица Школьная, дом 5, село Карамышево, 423119

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
**КАРМЫШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ**
**СОВЕТЫ**
Мәктәп урамы, 5 йорт, Кармыш авылы, 423119

тел./факс 8439642223 email: Karam.Cmn2@tatar.ru

№23 17.04.2026

Татарстан Республикасы
Чирмешән муниципаль районының
Кармыш авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының 2019 елның 7 февралендәге «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 96 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының 406 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кармыш авыл җирлеге Советы **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Кармыш авыл җирлеге Советының «Физик затлар мөлкәтенә салым турында» 2019 елның 07 февралендәге 96 номерлы карарына (Советның 11.06.2019 ел № 108, 28.09.2021 ел №45, 23.08.2024 ел №141, 26.12.2024 ел №156, 05.03.2025 ел №160 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә «2. Салым ставкаларын түбәндәге күләмдә билгеләргә:

1) 0,1 процент түбәндәгеләргә карата:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгән салым салу объектларындагы гаражлар һәм машина урыннары, шул исәптән салым салу объектларында урнашкан урыннар, Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына карата;

2) 0,2 процент түбәндәгеләргә карата:

- фатир; фатир өлеше;

- бүлмәләр;

3) 0,3 процент түбәндәгеләргә карата:

- торак йортлар; торак йортларның өлешләре;

- төзелеп бетмәгән объектлар,  мондый объектларның проектлана торган билгеләнеше торак йорт булган очракта;

- составына бер генә булса да торак йорт кергән бердәм күчемсез комплекслар;

4) 2025-2027 еллар чорына гомуми мәйданы 1000 квадрат метрдан артыграк булган административ-эшлекле үзәкләргә һәм сәүдә үзәкләренә (комплексларына) һәм алардагы урыннарга карата 1,2 процент:

- Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 7 пункты нигезендә билгеләнә торган исемлеккә кертелгәннәргә;

- агымдагы салым чорына Россия Федерациясе Салым кодексының 378.2 статьясындагы 10 пунктының икенче абзацында каралган салым салу объектларына;

2,5 процент түбәндәгеләргә карата:

- һәркайсының кадастр бәясе 300 миллион сумнан артып китә торган салым салу объектлары, проектлана торган билгеләнеше күпфатирлы йорт булган төзелеп бетмәгән объектлардан тыш»

5) башка салым салу объектларына карата 0,5 процент».

2. Әлеге карар 2026 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла һәм алар рәсми басылып чыккан көннән кимендә бер ай узгач һәм чираттагы салым чорының 1 числосыннан да иртәрәк булмаган вакытта үз көченә керә.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында бастырып чыгарырга (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының рәсми сайтында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

ТР ЧМР Кармыш авыл җирлеге
башлыгы, Совет рәисе Р.Р.Гатина